**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 30 » сентябрь 2016 ел** **№28**

## Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"2017 елда Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешегә, 1 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, балачак инвалидларыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерүдә катнашучылардан тыш, 450 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | - Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керә торган юлларга вак таш салу;<br><br>Яңа Кенәр авылы (Г. Тукай ур., с. Хисмәтуллин ур., Х. Фәтхуллин ур.),<br>Яңа Ашыт авылы (Вахитов ур.),<br>Шурабаш авылы, Чапаев ур., Палантай ур.),<br>Шура авылы (Яңа Алиф, | **898300,00**<br><br>446300,00<br><br>30150,00<br>86650,00<br><br>53950,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Гагарин ур.)<br>Байкал авылы (Г. Тукай ур.),<br>Яңа Сәрдә авылы (Х. Такташ),<br>Сөрде авылы (Совет ур., Киров ур.)<br>Югары Оры авылы (Совет ур., Тукай ур.)<br>Түбән Оры авылы (Г. Салихов ур., Тукай ур.),<br>Кызыл Яр авылы (Киров ур.) | 51100,00<br>30850,00<br>64750,00<br>42700,00<br>55750,00<br>36100,00 |
| | Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - мотопомп сатып алу:<br>Шурабаш авылы-1 данә,<br>Сөрде авылы-1 данә | **16000,00**<br>8000,00<br>8000,00 |
| | Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру. | - спорт мәйданчыгы төзелеше<br>Яңа Кенәр авылы | **575425,00** |
| | ИТОГО: | 1 | **1489725,00** |

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет ур., 10 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде ур., Совет ур., 48 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин ур., 17А йорт.

3. Әлеге карарны Яңа Кенәр авыл җирлеге Советына җибәрергә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.